**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

422750, село Большая Атня, улица
Ш.Марджани, дом 6

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы,
Ш.Мәрҗани урамы, 6нчы йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«21» март 2025 ел. № 102

**Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитетының “Әтнә муниципаль районында 2025 елга күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортта торак урыннары хуҗалары өчен торак бинаны тоту өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик индексын раслау турында” 31.01.2025 ел, №29 карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 158 маддәсенең 4 өлеше нигезендә, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2018 елның 06 апрелендәге 213/пр номерлы «Күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннары хуҗалары өчен торак бинаны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү буенча методик киңәшләрне раслау, торак урынын карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү, шулай ук мондый түләү күләмен үзгәртүнең чик индексларын билгеләү тәртибен билгеләү турында»гы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитеты карар чыгара:

1. Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитетының «Әтнә муниципаль районында 2025 елга күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында Карар кабул итмәгән күпфатирлы йорттагы торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап токтан өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик индексын раслау турында» 31.01.2025 ел, №29 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1нче пунктта “ 9” санын “10” санына алмаштырырга.

2. Әлеге карар 01.01.2025 елдан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында (http://atnya.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Әтнә район башкарма комитеты урынбасары М. Л. Халиковка йөкләргә.

Җитәкче А.Ф. Каюмов